ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# «Татарстан Республикасы территориясендә алкоголь продукциясен ваклап сату вакытына, шартларына һәм урыннарына карата өстәмә чикләүләр һәм Татарстан Республикасының кайбер закон актларының үз көчләрен югалтуын тану турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2015 елның 10 июнендә
кабул ителде

## 1 статья

«Татарстан Республикасы территориясендә алкоголь продукциясен ваклап сату вакытына, шартларына һәм урыннарына карата өстәмә чикләүләр һәм Татарстан Республикасының кайбер закон актларының үз көчләрен югалтуын тану турында» 2015 елның 6 мартындагы 10-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2015, № 3, № 4), түбәндәге эчтәлекле $2^1$ статья өстәп, үзгәреш кертергә:

**«$2^1$ статья**

Татарстан Республикасы территориясендә аз алкогольле тонусны күтәрә торган эчемлекләрне ваклап сату тыела, андый эчемлекләр дигәндә әлеге статья максатлары өчен «Аз алкогольле тонусны күтәрә торган эчемлекләр. Гомуми техник шартлар» ГОСТ Р 52845-2007 Россия Федерациясе милли стандарты нигезендә әзер продукция күләменең 1,2дән 9 процентка кадәрен этил спирты тәшкил иткән, составында кофеин һәм (яисә) башка тонусны күтәрә торган компонентлар була торган алкоголь продукциясе аңлашыла.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 60 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Президенты
вазыйфаларын вакытлыча башкаручы Р.Н. Миңнеханов

Казан,Кремль
2015 елның 1 июле
№ 49-ТРЗ